# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.2 статьясына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның  24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.2 статьясын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 –  8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1; Ватаным Татарстан, 2012, 20 июнь, 24 июль) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2.2 статья. **Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатының, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатының, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасының законлы таләпләрен үтәмәү**

Татарстан Республикасы дәүләт органының, җирле үзидарә органының, Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчалары исәбеннән тулысынча яисә өлешчә финанслана торган йә гамәлгә куючылары Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары булган оешманың, иҗтимагый берләшмәнең вазыйфаи затлары Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатының законлы таләпләрен үтәмәгән йә аның эшчәнлеген гамәлгә ашыруга каршылык тудырган өчен –

ике меңнән өч мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.

Әлеге статьяның беренче өлешендә күрсәтелгән вазыйфаи затлар Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатына, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле

органы депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына мәгълүмат (документлар, материаллар, мөрәҗәгатьләргә җаваплар) бирүнең билгеләнгән срокларын үтәмәгән, шулай ук аларга күрәләтә ялган мәгълүмат биргән өчен –

бер меңнән ике мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2013 елның 12 гыйнвары
№ 3-ТРЗ